МБОУ «АНТОНОВСКАЯ СОШ»

| | |
|---|---|
| РАССМОТРЕНО | УТВЕРЖДЕНО |
| ПЕДАГОГИЧЕСКОМ СОВЕТОМ | ДИРЕКТОР МБОУ «АНТОНОВСКАЯ СОШ» |
| МБОУ «АНТОНОВСКАЯ СОШ » | ВИХЛЯНСКИЙ А.Н. |
| ПРОТОКОЛ №1 | ПРИКАЗ №90 |
| ОТ 15 АВГУСТА 2024ГОДА | ОТ 15 АВГУСТА 2024ГОДА |

РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

ПО ПРЕДМЕТУ **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ЯЗЫК (ТАТАРСКИЙ) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ДЛЯ 1А КЛАССА,

(2 ЧАСА В НЕДЕЛЮ, 66 ЧАСОВ В ГОД)

(УРОВЕНЬ – БАЗОВЫЙ)

СОСТАВИТЕЛЬ: ГАЙНУЛЛИНА Г.М.

(УЧИТЕЛЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ,

ПЕРВАЯ КВАЛИФИКАЦИОННАЯ КАТЕГОРИЯ)

АНТОНОВКА, 2024/2025УЧЕБНЫЙ ГОД

**1 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ БУЛАРАК ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН ТАТАР ТЕЛЕ ФӘНЕННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

**(РУС ТӨРКЕМЕ, "СӘЛАМ" УМКСЫ НИГЕЗЕНДӘ )**

## I. АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасы системалы-эшчәнлекле юнәлешкә корыла һәм системаны барлыкка китерә торган төп компонент буларак нәтиҗә күрсәтелә. Бу - предмет, метапредмет, шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән рус телле балаларга татар теле һәм әдәби уку системасына да карый. Ягъни рус телле укучыларга татар теле укыту системасының барлык компонентлары: программалар, укыту-методик комплектлары, дәрес процессы, контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – барысы да бер максатка – нәтиҗәгә хезмәт итә.

Билгеле булганча, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасында белем бирү системасының төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү. Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 нче маддәсендә һәм "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы" Законда күрсәтелгәнчә, Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү милләтләрнең үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә. Татар теле, дәүләт теле буларак, барлык урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләрендә төп уку предметларының берсе булып тора.

Тәкъдим ителә торган программа "Сәлам" укыту- методик комплекты ярдәмендә 1нче сыйныф укучыларына белем бирүне планлаштыру, уку-укыту процессын тәэмин итү максатын күздә тота. Ул "Сәлам" УМКсы ярдәмендә татар телен дәүләт теле буларак укыту буенча эш программасын төзү өчен нигез булып тора һәм ул укыту предметының мәҗбүри өлешен тәшкил итә. Мәктәпнең эш үзенчәлегеннән чыгып, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленеше һәм материалны өйрәнү эзлеклелеген, эчтәлекне киңәйтү, шулай ук укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру юлларын башкачарак тулыландыруны теләп, укытучылар эш программасына үзгәрешләр кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының аңлатма язуында чагылыш табарга тиеш.

**Рустелле укучыларга татар телен дүәләт теле буларак укытуның төп максатлары**

Татар теленә өйрәтүнең төп максатлары: укучыларның аралашу даирәсен, аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча укучыларда коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы) формалаштыру; укучының танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү; татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү; укучыларны мәдәниятара диалогка тарту; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру.

1 нче сыйныф өчен сайланган эчтәлек укучыны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, укуның универсаль гамәлләрен формалаштыру максатларына хезмәт итә. Укыту процессы коммуникатив методның төп принципларын исәпкә алып оештырыла. Ул аралашуга аралашу аша өйрәтү принцибына корылган. УМК яңа гына мәктәпкәчә уку һәм тәрбия бирү үчреждениясен тәмамлаган балаларны уен прцессы аша телгә өйрәтү шартларын тудыра, ягъни тормышта телне куллану шартларына якынлаштыра. Бу укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-

омтылышларын, индивидуаль-психик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыруны тәэмин итә. Аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль кулланауын тәэмин итү үрнәк күнегүләр бирү һәм ситуацияләр тудыру аша тормышка ашырыла. УМКда телне функциональ төстә өйрәнү принцибы һәрдаим истә тотыла, ягъни лексик-грамматик материал коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнелә. Шулай ук ана телен исәпкә алу принцибы да исәпкә алына.

## Укытуның шәхескә кагылышлы, предметара, предмет нәтиҗәләре

1 нче сыйныфта телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәниятләргә карата ихтирам хисе уята, укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга һәм объектив бәяләргә мөмкинлек бирә.

Укучының үзенә һәм әйләнә-тирәсендәге кешеләргә карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре** формалашкан булуы күзаллана:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү;

– туган илеңнең, туган ягыңның, анда яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм сәнгате турында хәбәрдар булу;

– укуга, үзлегеңнән белем алуга җаваплы карау;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– *гаилә, дуслык* төшенчәләрен кабул итү, башкаларга карата түземле һәм кайгыртучан, ихтирамлы булу;
– үз-үзеңне эстетик яктан тәрбияләү;
– башкаларны тыңлый һәм аңлый белү, итагатьле әңгәмәдәш булу, үзара аңлашуга ирешү;
– белем алу һәм башка эшчәнлек барышында үз яшьтәшләрен, өлкәннәр белән мөнәсәбәт урнаштыра һәм аралаша белү.

Татар теле укытуның **предметара нәтиҗәләре:**

татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган укуның ***танып белү, регулятив, коммуникатив*** гамәлләрен формалаштыруга хезмәт итә.

Дәресләр вакытында укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график символлар, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; алдан әзерләнеп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрән*ә; у*кучыларда, интерактив дәреслек, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре**:*

– фикер йөртү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләрне табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү алгоритмнарын мөстәкыйль төзи алу;
– объектларны чагыштыру нигезендә уртак билгеләрне күрсәтү;
– төп һәм икенчел мәгълүматларны аеру, укылган яки тыңланган эчтәлеккә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели алу;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыру, нәтиҗәле эш алымнарын табу;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләргә ия булу;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерләү һәм тәртиптә тоту.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтенә ия булу;
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәш белән сөйләшүне башлау, дәвам иттерү, уңышлы тәмамлау.

Татар теленә өйрәтүнең **предмет нәтиҗәләре**:

***Сөйләү***

- сорау һәм җавап репликаларын дөрес кулланып, тәкъдим ителгән ситуация буенча диалог оештыру (һәр укучының репликалар саны 3тән ким булмаска тиеш);
- укылган яки тыңланган текстның эчтәлеге буенча сорау бирә белү;
- өйрәнелгән лексик тема буенча кечкенә күләмле бәйләнешле текст төзеп сөйләү (җөмләләр саны 3тән ким булмаска тиеш);
- укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү.
- укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген сөйләгәндә, җөмлә калыпларын, лексик берәмлекләрне урынлы куллану.
- өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына жавап бирү һәм сораулар куя белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.
- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

- тәкъдим ителгән терәк сүзләр ярдәмендә укылган текст яисә караган рәсем (фильм) буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

- үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә күләмле мәгълүмат бирә белү (җөмләләр саны 3тән ким булмаска тиеш).

***Тыңлап аңлау***

- тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;

- сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;

- 0,5 минутлык бәйләнешле текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү;

- дәрестә катнашучыларның җанлы сөйләмен тыңлап, эчтәлегенә төшенү.

***Уку***

-татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;

-хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;

-дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;

- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;

**Язу**

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;

- өйрәнелгән сүзләр белән җыйнак җөмләләр язу;

- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;

- укылган (тыңланган) текстның эчтәлеге буенча гади сорауларга җаваплар язу.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре**

***Сөйләмнең фонетик ягы***

– татар сөйләмен фонетик яктан дөрес оештыру;
– татар авазларын дөрес әйтергә өйрәнү;
– аерым сүзләрдә басымны дөрес кую;
– әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен аеру;
– ритм һәм интонация үзенчәлекләрен исәпкә алып, җөмләләрне дөрес әйтү;
– өйрәнелгән сүзләрне дөрес әйтү, уку.

***Сөйләмнең лексик ягы***

– аралашу барышында, коммуникатив максаттан чыгып, актив лексикадан файдалану;
– өйрәнелгән аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне һәм сүзтезмәләрне тану.

***Сөйләмнең грамматик ягы***

– өйрәнелгән сөйләм калыпларын аралашу вакытында дөрес куллану.

**Социаль-мәдәни күнекмәләр**

Татар этикет (сәламләшү, саубуллашу, рәхмәт белдерү) нормаларын, туганлык атамаларын белү.

**Махсус күнекмәләр**

УМКның мультимедиа әсбапларыннан, башка татар сайтларыннан файдалану.” Сәлам” УМКсы нигезендә, 1нче сыйныфта татар теле фәне дәреслек нигезендә алып барыла (Сәлам.1.1). Тел дәресләрендә өйрәнелгән төрле текстлар (монологик, диалогик, шигъри һ.б.) ярдәмендә актуальләштерелә.

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

Телдән һәм язма сөйләмнең эчтәлеге белем һәм тәрбия бирү максатларыннан, шулай ук укучыларының яшь үзенчәлекләре һәм мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләнә.  Эш программасы  66 сәгатькә исәпләнгән һәм атнада 2 сәгать дәресләр булуны күзаллап төзелгән.

| **Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек** | **Якынча сәгатьләр саны** |
|---|---|
| Сәлам! | 5 |
| Мәктәп | 7 |
| Саннар | 8 |
| Төсләр | 7 |
| Гаилә | 9 |
| Уенчыклар | 9 |
| Шөгыльләр һәм хәрәкәтләр | 9 |
| Вакыт | 9 |
| Барлыгы | 66 сәг. |

**Тел материалы**

| Тема | Лексика | Сөйләм калыплары |
|---|---|---|
| Сәлам! | Исәнме/сез!<br>Сәлам!<br>Сау бул(-ыгыз)!<br>Рәхмәт<br>Начар<br>Шәп<br>Яхшы<br>Әйе<br>Юк<br>Мин<br>Син<br>ул | Хәерле иртә (көн, кич)!<br>Тыныч йокы!<br>Син кем?<br>Мин - ...<br>Хәлләр ничек?<br>Син Алсумы?<br>Әйе, Алсу.<br>Юк, Алсу түгел!<br>Бу - .. мы/-ме? |
| Мәктәп | Мәктәп<br>Сыйныф<br>Такта<br>Акбур<br>Чүпрәк<br>Бетергеч<br>Китап<br>Дәфтәр<br>Каләм<br>Көндәлек<br>Укучы<br>Укытучы | Бу нәрсә?<br>Ул кем?<br>Бу … түгел.<br>... кайда?<br>Сыйныфта кем (нәрсә)... бар/ юк?<br>Укучы сыйныфта.<br>Китап (...) өстәлдә.<br>Китаплар (...) партада.<br>Каләмнәр пеналда. |
| Саннар | Бер<br>Ике<br>Өч<br>Дүрт<br>Биш<br>Алты | Ничә... бар/юк?<br>- Сиңа ничә яшь?<br>Миңа (аңа) .... яшь.<br>Кемгә ... кирәк?<br>Саннар юк. |

| | | |
|---|---|---|
| | Җиде<br>Сигез<br>Тугыз<br>Ун<br>Ничә? | |
| Төсләр | Кара<br>Күк<br>Сары<br>Яшел<br>Көрән<br>Кызыл<br>Кызгылт сары<br>Соры<br>Зәңгәр<br>Ак<br>Ал<br>Шәмәхә<br>Кара<br>Нинди?<br>Матур<br>Күбәләк<br>Чәчәк | ... нинди?<br>Лимон (...) нинди төстә?<br>Лимон (...) сары (…) төстә.<br>Кызыл чәчәк вазада. |
| Гаилә | Гаилә<br>Әти<br>Әни<br>Әби<br>Апа<br>Бабай<br>Сеңел<br>Зур<br>Кечкенә<br>Яшь | Синең исемең ничек?<br>Минем исемем...<br>Аның ...(-ы/-е/ –сы/-се) бармы?<br>Әйе, ... бар. Юк.<br>Минем ...(-ем/-ым/-м) бар/юк.<br>Синең ...(- ың/-ың/-ң) бар/юк.<br>Аның ...( -сы/-се/-ы/-е) бар/юк. |

| | | |
|---|---|---|
| | Карт<br>Эне<br>Һәм<br>Абый | |
| Уенчыклар | Машина<br>Уенчык<br>Бөтерчек<br>Уен<br>Курчак<br>Туп<br>Шакмак<br>Быргы<br>Очкыч | Миндә ... бар/юк.<br>Мин ... белән уйныйм.<br>Син нәрсә белән уйныйсың?<br>Син кибеттә нәрсә аласың?<br>Мин кибеттә уенчыклар алам.<br>Ул кибеттә туп ала. |
| Шөгыльләр һәм хәрәкәтләр | Кара<br>Тыңла<br>Әйт<br>Утыр<br>Яз<br>Рәсем яса<br>Җырла<br>Укы<br>Эч<br>Аша<br>кил<br>Кит<br>Кер<br>Чык<br>Тукта<br>Сөрт | Син утыр!<br>Син сыйныфка кер.<br>Ул сыйныфка керә.<br>Син сыйныфтан чык.<br>Ул сыйныфтан чыга. |
| Вакыт | көз<br>яз<br>кыш | Сәгать ничә?<br>Хәзер яз көне.<br>Мин төнлә йоклыйм. |

| | | |
|---|---|---|
| | җәй<br>ай<br>хәзер<br>кайчан?<br>иртән<br>көндез<br>кичен<br>төнлә<br>йокла<br>сәгать<br>ял көне | |

**Белем бирүне материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү**

"Сәлам!" УМКсы ярдәмендә татар теленә өйрәткәндә, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдалану тәкъдим ителә: карточкалар, стикерлар, интерактив дәреслек, аудиодиск, "Сәлам!" сайты (http://selam.tatar/), өстәмә татар сайтлары; электрон китапханә.

**Өстшмә интернет ресурслар:**

https://www.youtube.com/user/balarf

http://watan.su/balalar-bulmase/25-multfilmnar/408-tatarmultfilm

http://www.belem.ru

http://kitap.net.ru

Онлайн школа EF-АНА ТЕЛЕ: http:// **anatele.ef.com.**

**Рус телле укучыларның татар теленнән белем һәм күнекмәләрен тикшерү төрләре.**

| № | Эш төрләре | 1нче сыйныф |
|---|---|---|
| 1. | Тыңлап аңлау | 0,5-1 минут |
| 2. | Диалогик сөйләм | 3-4 реплика |
| 3. | Монологик сөйләм | 3-4 фраза |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Һәр тема буенча аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү | 3 күнегү |
| 5. | Уку | 20-25 сүз |
| 6. | Язу: | |
| | күчереп язу (гади җөмлә) | 2-3 җөмлә |
| | сүзлек диктанты | 3-5 сүз |

# 1 НЧЕ СЫЙНЫФ ӨЧЕН КАЛЕНДАРЬ -ТЕМАТИК ПЛАН

| Дә рес № | Дәрес темасы | Дә-рес са-ны | Төп эчтәлек (өйрәнелә торган лексика һәм сөйләм калыбы) | Көтелгән нәтиҗә | | | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Контроль эш төрләре | Үткәрү вакыты план / факт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | метапредмет | предмет | шәхси | | | |
| **“Сәлам!” – 5 сәг.** | | | | | | | | | |
| 1 | Сәламләшү. | 1 | Исәнмесез. Сәлам. Мин ... . Син кем? | Татар һәм рус сәламләшү этикеты нормаларын чагыштыра белү | Татарча сәламләшә алу. | Бер-береңә карата игътибарлы һәм ихтирамлы булу. | Аудиматериалны тыңлау, кабатлау; кечкенә диалог төзү. “Танышу” уенын уйнау. | Үзара сәламләшү. | |
| 2 | Хәл сорашу. | 1 | Хәлләр ничек? Рәхмәт. Яхшы. Шәп. Бик яхшы. Начар. | Татарча һәм русча хәл сорашу кагыйдәләрен белү. | Бер-береңнең хәлен сорый һәм сорауга җавап бирә белү. | Итагатьле әңгәмәдәш булу. | Аудиматериалны тыңлау, кабатлау; кечкенә диалог төзү. “Ишарәләр белән күрсәт” уенын уйнау, сорауларга җавап бирү. | Парлап эшләү: сөйләшү. | |
| 3 | Раслау яки инкяр итү. | 1 | Бу ...-мы/-ме? Әйе. Юк. | Үзара аңлашуга ирешү . Дәресләрдә активлык күрсәтү. | Сорау һәм аңа кыска җавап бирә алу | Әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү. | Аудиматериалны тыңлау, кабатлау; кечкенә диалог төзү. “Әверелү” һәм “Чылбыр” уеннарын уйнау. Җыр тыңлау. | Әңгәмә кору. | |
| 4 | Саубуллаш у | 1 | Сау бул! Сау булыгыз! | Дәрес барышында үз нәтиҗәләреңне тикшереп бару һәм сөйләмгә төзәтмәләр кертә алу. | Татарча саубуллаша белү | Парларда һәм төркемнәрдә эшли алу.. | Сүзләрне тыңлау һәм укытучы артыннан кабатлау; үрнәк буенча диалон төзү, “Ишарәләр белән күрсәт” уенын уйнау, сорауларга җавап бирү. | Парлашу һәм диалог сөйләү. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Тикшерү һәм бәяләү | 1 | Өйрәнелгән материалның истә калуын бәялә. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | **Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.** | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | “Таныш”, “Кем ул?”, “сүз белән әйт” биремнәрен үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| **“Мәктәп” – 7 сәг.** | | | | | | | | | |
| 6-7 | Мәктәптәге предмет һәм җиһазлар | 2 | Сыйныф, такта, чүпрәк, акбур, бетергеч, китап, дәфтәр, каләм. | Парларда эшли белү. | Мәктәптә куллана торган төп предметларның атамаларын белү.. | Укуга, белем алуга җаваплы карау. | Сүзләрне күмәк рәвештә әйтү һәм истә калдыру; парлап диалоглар төзү; “Парыңны тап”, “дустыңны тап”, “Кем тизрәк” һ.б. уеннарны уйнау. | Фронталь әңгәмә. Телдән сөйләмне тикшерү. | |
| 8 | Бу нәрсә? Бу кем? | 1 | Бу нәрсә? Бу кем? Бу — ... . Бу китап түгел. Бу укытучы түгел, ә укучы. | Башкаларны тыңлый һәм аңлый белү, итагатьле әңгәмәдәш булу. | Сорауга раслап яки инкяр итеп җавап бирә белү. | Мәктәп тормышын күзәтү. | Аудиоматериалны тыңлау, сорауларга җавап бирү, әңгмәдәшкә сорау бирү. “Бу кем?”, “Бу нәрсә?” , “Күзеңне йом!”уенын уйнау. | Диалог сөйләү. | |
| 9-10 | Предметның урыны | 2 | Кайда? Сыйныфта, мәктәптә, партада, пеналда... бар/юк. | Үзара аңлашуга ирешү. | Предмет һәм затларның урынын, булу/ булмавын әйтә белү | Аралаша белү сәләтенә ия булу.. | Яңа сүзләрне тыңлау һәм кабатлау; диалогны тулыландыру; “ Сыйныфта бар”, “Чылбыр” уенын уйнау, эш дәфтәрендә 3нче күнегүне башкару. “Безнең мәктәп” җырын тыңлау.. | Сыйныфтагы предметлар турында сөйләү. | |
| 11 | Бер һәм күп предметлар, затлар | 1 | -лар/-ләр формасы; китаплар, дәфтәрләр, укучылар, | Белем алу һәм башка эшчәнлек барышында үз яшьтәшләрең, өлкәннәр белән | Предмет һәм затларның бер яки бердән күп булуы турында әйтә белү. | Матур итеп үз фикереңне әйтергә өйрәнү. | Яңа сүзләрне, җөмләләрне аудиоязмада тыңлау, күмәк рәвештә әйтү; “ Кемнәр/нәрсәләр бар/юк?”, “ Җавап бир”, | Сыйныфтагы предметлар турында җөмләләр әйтү. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 3, | | көннәр, каләмнәр; бу.. — болар.. | мөнәсәбәт урнаштыра һәм аралаша белү. | | | “Предметларны тап” биремнәрен үтәү. Җыр тыңлау. | | |
| 12 | Тикшерү һәм бәяләү | 1 | Өйрәнелгән материалның истә калуын бәялә. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | “Сүзне белү”, “Коллаж төзү?”, “Командада эшләү” биремнәрен үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| **“Саннар” – 8 сәг.** | | | | | | | | | |
| 13-14 | 1нче дистә саннары | 2 | Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун. Ничә? Сан. | Мәгълүматны туплау өчен, кирәкле эш башкару | Беренче дистә микъдар саннарын татарча әйтә белү, аларны сөйләмдә куллана алу.. | Үз-үзеңне эстетик яктан тәрбияләү. | Саннарны әйтергә, татарча санарга өйрәнү. “Ватык телефон” уенын уйнау. “ “сана һәм хәрәкәтләр яса”. “Синдә ничә?” биремнәрен үтәү. | Саннарны буяу һәм әйтү. | |
| 15-16 | Сиңа ничә яшь? | 2 | Яшь. Сиңа ничә яшь? Сиңа дүрт яшьме? Миңа 7 яшь. Аңа ничә яшь? Аңа 6 яшь. | Аралаша белү сәләтенә ия булу. Татар һәм рус телендә чагыштырып өйрәнү. | Татарча әңгәмәдәшнең яшен сорый белү.. | Итагатьле әңгәмәдәш буллу. | “Аю белән танышу”, “Сиңа ничә яшь?” уенын уйнау. Сорау һәм җавап бирү. “Саннар” җырын өйрәнү. | Үзем турында мәгълүмат җиткерү. | |
| 17 | Кирәк, кирәкми. | 1 | Кемгә кирәк? Миңа, сиңа, аңа. Кирәк/ кирәкми | Татар һәм рус телендә кирәклекне чагыштырып әйтә белү. | Кирәк әйбер турында әйтә алу. | Матур итагатьле сорау һәм җавап бирә белү | “сүзне тап”, “Куян, сиңа нәрсә кирәк?”, “ Сөйләш” биремнәрен үтәү. Аудиоматериал белән эш. Җыр җырлау. | Эш дәфтәрендә 4енче күнегүне башкару. | |
| 18-19 | Кемгә кирәк? | 2 | Кемгә кирәк? Ничә ... кирәк? | Шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы булу | Кирәклекне, затларны белдерә алу. | Әңгәмәдәш белән сөйләшүне башлау, дәвам иттерү, уңышлы тәмамлау. | Коммммникатив биремнәр эшләү, уеннар уйнау. | Эш дәфтәрендә 5енче күнегүне башкару. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | һәм аны яхшы өйрәнергә теләү. | | | | | |
| 20 | Тикшерү һәм бәяләү | 1 | Өйрәнелгән материалның истә калуын бәялә. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | “Унга кадәр сана”, “Саннарны дөрес әйт”, “Укучылар һәм укытучылар” биремнәрен үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| **“Төсләр” - 7 сәг.** | | | | | | | | | |
| 21-22 | Төп төсләр | 2 | Зәңгәр, кызыл, яшел, сары, шәмәхә, чәчәк, күбәләк, түгел, нинди? | Үз-үзеңне эстетик яктан тәрбияләү | Төп төсләрне татарча әйтә, алар белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзи белү. | Табигатьтәге төсләргә соклану. | Аудиоязма белән эш. “Төсләрне ата”, “парыңны тап”, “Истә калдыр” биремнәрен үтәү, “Кайтаваз” уенын уйнау. | “Рәсемле бирем” | |
| 23 | Өстәмә төсләр | 1 | Әдәпле сөйләм берәмлекләре кулланып укучыларда татар телен өйрәнүгә омтылыш булдыру. | Парларда, төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү. | Төсләрне сөйләмдә куллана белү. | Үз-үзеңне эстетик яктан тәрбияләү. | “ Истә калдыр”, “ Тыңла һәм әйт”, “Сора” биремнәрен үтәү, “Пинг-понг”, “Кем җитезрәк?”, “Нәрсә юк?” уеннарын уйнау. | Коммуникатив биремнәр эшләү. | |
| 24 | Һәр нәрсәнең үз төсе бар | 1 | Соры, күк, ал, шар, җыр. | Тирә-яктагы предметларны, аларның төсләрен күзәтү. | Предметларның төсләре турында сорау бирә белү. | Парлап эшли алу. | Парлашып һәм төркемнәрдә күнегүләр башкару, уеннар уйнау (мәсәлән, “Кайтаваз”, “Кар өеме” һ.б.). “Төсләр” җырын тыңлау. | “Пеналны тутыр” уены | |
| 25 | Салават | 1 | Кызыл. Сары. | Күнегүләрне | Тирә-яктагы | Әңгәмәне башлый, | “Әверелү”, “кәләпүш”, | Күмәк әңгәмә | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | күпере | | Яшел. Зәңгәр. Шәмәхә. Чәчәк. Күбәләк. Кызгылт сары. Көрән. Кара. Ак. Соры. Күк. Ал. Салават күпере. Шар. Җыр. Төс | башкарганда, көндәлек тормыш белән бәйләнештә күзаллый белү. | төсләрне атый белү. | дәвам итә һәм тәмамлый алу. | уеннарын уйнау. “Предметны бел”, “Табышмакны чиш”, “Табышмак әйт” биремнәрен үтәү. Җыр җырлау. | кору. | |
| 26 | Кабатлау | 1 | Кызыл. Сары. Яшел. Зәңгәр. Шәмәхә. Чәчәк. Күбәләк. Кызгылт сары. Көрән. Кара. Ак. Соры. Күк. Ал. Салават күпере. Шар. Җыр. Төс. | Итагатьле әңгәмәдәш булу. | Төсләр белән татарча гыйбарәләр әйтә алу. . | Диалоглар, сорауларга җавап биреп, күнегүләр эшләп, сыныфташларга карата ярдәмчел булу. | “Портфельдә ниләр бар?”, “Төркемгә берләш”, “Буя һәм ата” биремнәрен үтәү. Җыр башкару. | Карточкалар белән эш | |
| **27** | Тикшерү һәм бәяләү | 1 | Өйрәнелгән материалның истә калуын бәялә. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | Карточкалар белән эш, ктөркемнәрдә биремнәр башкару. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| **“Гаилә” – 9 сәг.** | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28-29 | Гаиләдә кемнәр бар? | 2 | Бабай, әби, әти, әни, апа, абый, сеңел, эне. | Гаилә әгъзалары турында туган тел мәгълүмате белән татарча белгәннәрне чагыштыра алу. | Гаилә әгъзаларын белдергән сүзләрне дөрес әйтә, сөйләмдә куллана белү. Аралаша белү сәләтенә ия булу. | Гаиләңә карата ихтирамлы булу. . | Аудиоязмала белән эш. “Гаиләдә кемнәр бар”, “Рәсемдә кем?”, “Бу кем?” биремнәрен үтәү, “Кайтаваз” уенын уйнау. | Эш дәфтәрендәге 1нче күнегүне башкару. | |
| 30-31 | Гаиләм | 2 | Гаиләм зур/кечкенә. Синең гаиләң зурмы, кечкенәме? | Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү. | Гаиләне зурлык-кечкенәлеккә карап тасвирлый белү. | Үз гаиләң белән горурлану. | Аудиоязма белән эш, сорауларга җавап бирү. “Бармак” уенын уйнау, “Кызыклы гаилә” турында әңгәмә кору. | “Зур-кечкенә” уены. | |
| 32-33 | Туганнарым | 2 | Апа, абый, сеңел, эне | Шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү. | Якын туганнарың турында сөйли белү. | Сыйныфташларны якын туганнарың белән таныштыру. | аудиоматериал белән эш. “Чылбыр” уенын уйнау. | Эш дәфтәрендәге 10нчы күнегүне башкару. | |
| 34 | Сыйныфташның гаиләсе | 1 | Аның ...-ы/-е/ -сы/-се | Гаилә әгъзалары арасында тату мөнәсәбәтләр булдыру. | Гаилә әгъзалары белән таныштыра белү. | Әхлакый кагыйдәләрне үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау. | Тыңлап аңлауны тикшерү. Аудиоязмалар белән эшләү. “Гаилә” җырын өйрәнү. | Рәсем буенча лексиканы кабатлау. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 35-36 | Кабатлау | 2 | Гаилә, әби, бабай, әти, әни, апа, абый, эне, сеңел, яшь, карт, зур, кечкенә, Синең исемең ничек?Минем исемем..., Синең исемең... Аның ...-сы/-се. | Әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, уңышлы тәмамлый алу. | Гаилә һәм аның әгъзалары турында мәгълүмат бирә белү. | Гаиләңә ихтирамлы карау, аның белән горурлану. | Гомумиләштереп нәтиҗә чыгара, сораулар биреп анализлый алу. “Шәҗәрә” агачы ясау һәм аның буенча әңгәмә кору. | Эш дәфтәрендә 4нче күнегүне башкару. | |
| 37 | Тикшерү һәм бәяләү | 1 | Өйрәнелгән материалның истә калуын бәялә. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | “Сора һәм җавап бир!”, “Гаиләң турында сөйлә”, “Тату гаилә” биремнәрен үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| **“Уенчыклар”- 10 дәрес** | | | | | | | | | |
| 38 | Татар авазлары. | 1 | [А],[Ә], [М], [О],[Ө], [Ч] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 39 | Уенчыклар ым | 1 | Машина, уенчык, бөтерчек, уен, курчак, туп, шакмак, робот, барабан, быргы, очкыч. | Уенчыклартурын да тормыштагы һөнәрләр белән бәйләп сөйли белү. | Уенчыкларның татарча атамаларын белү. Аралаша белү сәләтенә ия булу. | Үз-үзеңне эстетик яктан тәрбияләү. | “Тыңла”, “Тап”, “Тәртипкә сал” биремнәрен башкару, “Йомык күзләр” уенын уйнау. | “Тасвирла” уенын уйнау | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 40 | Миндә ул бар! | 1 | Миндә ...бар/юк, синдә нәрсә бар/юк? | Башкаларны тыңлый һәм аңлый белү. | Уенчылар турында сөйли белү. | Уеньчыклар турында зңгәмә кору сәләтенә ия булу. | Өйдән алып килгән уенчыклар белән таныштыру. Аудиоязма белән эш. “Пантомимо”, “баскетбол” уеннарын уйнау. | Эш дәфтәрендәге 2нче күнегү. | |
| 41 | Мин уйныйм. | 1 | «Мин ... белән уйныйм», «Син нәрсә белән уй - ныйсың?» , «Ул нәрсә белән уйный?» | Белем алу барышында үз яшьтәшләрең белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыра белү. | Нәрсә белән уйнау турында хәбәр итә алу; | Әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; | Аудиоязма белән эшләр башкару. “Нәрсә югалды?” уенын уйнау. “Уенчыклар” җырын тыңлау. | Эш дәфтәрендә 3нче күнегүне башкару. | |
| 42 | Татар авазлары. | 1 | [х], [һ], [р], [ц], [щ], “ё “ | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 43 | Уенчык алам | 1 | Мин кибеттә уенчыклар алам. Син кибеттә нәрсә аласың? Ул кибеттә туп ала. | Төрле һөнәрләрдә кулланыла торган предмет атамаларын истә калдыру. | Кибеттә уенчыклар сайлау турында әйтә алу. | Укуга, үзлегеңнән белем алуга җаваплы карау. | Аудиоязма белән эш. “уенчыклар кибете” уенын уйнау. | Сорауларга җавап бирү. | |
| 44 | Кабатлау | 1 | Машина, уенчык, бөтерчек, уен, курчак, туп, шакмак, робот, барабан, быргы, очкыч. Миндә ...бар/ю | Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү. | Уенчыклар алу, алар белән уйнау турында хәбәр итү. | Башкаларны тыңлый һәм аңлый белү. | Уенчыклар турында әңгәмә кору. “Балык”, “Кәләпүш”, “Кем җитез” уеннарын уйнау. Җыр җырлау. | Эш дәфтәрендә күнегү башкару. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | к, синдә нәрсә бар/юк?Мин ... белән уйныйм», «Син нәрсә белән уй - ныйсың?» , «Ул нәрсә белән уйный?»Мин кибеттә уенчыклар алам. Син кибеттә нәрсә аласың? Ул кибеттә туп ала. | | | | | | |
| 45 | Татар авазлары. | 1 | [ы],[и], [к], [къ] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 46-47 | Тикшерү һәм бәяләү | 2 | Өйрәнелгән материалның истә калуын бәяләә. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | “Сора һәм җавап бир!”, “Уенчыгың белән таныштыр”, “кем тизрәк?” биремнәрен үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| **“Шөгыльләр һәм хәрәкәтләр” – 10 сәг.** | | | | | | | | | |
| 48 | Гамәлләр | 1 | Кит, кил, бас, кара, тукта, | Физкультура дәресендә | Көндәлек тормышта еш | Сыйныфташларыңа карата ихтирамлы | Аудиоязма белән эшләү. “Хәрәкәтне бел”, “Гали | Эш дәфтәрендә | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | утыр, кер, чык. Ул китә; ул килә; ул баса; ул карый; ул туктый; ул утыра; ул керә, ул чыга. | кулланыла торган командаларны истә калдыру. | кулланыла торган эш һәм хәрәкәтләрне татарча әйтә белү. | һәм игътибарлы булу. | нишли?” уеннарын уйнау. | 1нче күнегүне башкару. | |
| 49 | Татар авазлары. | 1 | [у],[ү], [г], [гъ] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 50 | Сыйныфта нишлим? | 1 | Сөрт, яз, укы, тыңла | Татар һәм рус телләрендәге хәрәкәтне белдерү формаларын чагыштыру. | Дәресләрдә еш кулланылган боерыкларны аңлау; | Шөгыльләр турында белергә омтылу . | “Кем нишли?” бу турыда сөйләшү. “”Боерыкны үтә”, “Хәрәкәтне бел” уеннарын уйнау, | Индивидуаль биремнәрне үтәү. | |
| 51 | Сорау һәм тәкъдим итү | 1 | Бир — бирә, ал — ала, мә. | Гамәлләрне рус теленә тәрҗемә аша аңлату. | Кирәк әйберне сорый һәм ала белү. | Башкаларның ни эшләүләре турында мәгълүматларын тыңлый һәм аңлый белү. | Аудиоязма белән эш. Сораулар куеп җөмләләр төзү. “ Миңа бир”, “дөрес-ялгыш”, “Боерыкны үтә” биремнәрен үтәү. | Кирәкле саннарны куеп 6 нче күнегүне эшләү. | |
| 52 | Татар авазлары. | 1 | [йэ], [йы] ], [н], [н] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 53 | Ул нишли? | 1 | Эч — эчә, уйна — уйный | Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, | Татарча дөрес сөйләшә белү. | Әхлакый кагыйдәләрдә | Аудиоязма белән эшләү. “Хәрәкәтләрне күрсәт”, | Эш дәфтәрендә | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | аңа туры килерлек җавап бирә белү/ | | ориентлашу. | “Әйе -юк” уеннарын уйнау. Җыр өйрәнү. | 5нче күнегүне башкару. | |
| 54-55 | Кабатлау | 2 | Үзләштерелгән белемнәрне системага салу. | Мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару. | Хәрәкәтләр һәм шөгыльләр турында хәбәр итә белү. . | Белем алу һәм башка эшчәнлек барышында үз яшьтәшләрен, өлкәннәр белән мөнәсәбәт урнаштыра һәм аралаша белү. | “Тыңла һәм санын әйт”, “Тикшер”, “Кунак”, “Төсләр” биремнәрен башкару. Сорауларга җавап бирү. Җыр җырлау. | Сорауларга җавап бирү. | |
| 56 | Татар авазлары. | 1 | [э], [в], [ф], [w] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 57 | Тикшерү һәм бәяләү | 1 | Өйрәнелгән материалның истә калуын бәялә. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | “Хәрәкәт ясa”, “Хәрәкәтне дөрес әйт”, “Укучылар һәм укытучылар” биремнәрен үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| **“Вакыт” – 10 сәг.** | | | | | | | | | |
| 58 | Ел фасыллары белән танышу | 1 | Көз, яз, кыш, җәй, көз көне, кыш көне, яз көне, җәй көне. | Ел фасылларына бәйле әйләнә-тирә мохитның үзгәрешләрен күзәтү. | Ел фасыллары атамаларын татарча әйтә белү, алар белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзи алу. | Табигатьне күзәтә һәм күзәтүләрне сөйләмдә куллана белү. | Аудиоязма белән эш. “Кайтаваз”, “Җылы – салкын”, “Шәп җырчы”, “Кәләпүш” уеннарын уйнау. | Әңгәмә кору. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 59 | Татар авазлары. | 1 | [йа], [йә], [д], [т] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 60 | Татар авазлары. | 1 | [з], [с], [й], [б], [п] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 61 | Айлар | 1 | Ай, кыш айлары, җәй айлары, яз айлары, көз айлары, декабрь, гыйнвар, февраль, хәзер, кайчан? | Һәр айның үзенчәлеген белү. | Ай атамаларын өйрәнү һәм сөйләмдә дөрес куллану | Татарча матур сөйләү. | “Оркестр”, “Ел фасыллары”, “Бу кайчан була?”, уеннарын уйнау. | Эш дәфтәрендәге 2нче күнегүне башкару. | |
| 62 | Тәүлек | 1 | Иртә, иртән, көн, көндез, кич, кичен, төн, төн -лә, йокла! | Табигать белеме нигезендә тәүлек үзгәрешләрен белү | Тәүлек вакытлары турында әйтә белү. | Тәүлек вакытларындагы үзгәрешләрне күрә һәм чагыштыра белү. | “ Кәләпүш”, “Алкышлар”, “Туплы” уеннарын уйнау. Карточкалар белән эш. “Вакыт” җырын өйрәнү. | Төркемнәрдә эшләү. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 63 | Сәгать | 1 | Сәгать, сәгать ничәдә? Сәгать биштә | Вакыт турында әңгәмәне башлый, дәвам итә һәм тәмамлый алу. | Иртән, көндез, кич нәрсә эшләү турында әйтә белү. | Әңгәмәдәшкә ихтирамлы һәм игътибарлы булу | Аудиоматериал белән эш. “Оркестр”, “Сорау-җавап”, “Дөрес – дөрес түгел уеннарын уйнау. Диалог төзү, сөйләшү. | Эш дәфтәрендәге 4нче күнегүне башкару. | |
| 64 | Татар авазлары. | 1 | [ж], [ж], [ш],“ъ”, “ь”, [л] | Татар һәм рус авазлары арасындагы аерманы белү | Татар авазларын дөрес әйтергә һәм алар кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү | Дөрес матур сөйли һәм яза белү. | “Дөрес әйт”, “Сүзләрне тап”, “Матур яз” һ.б. биремнәрне үтәү. | Эш дәфтәрендә хәрефләрне язу. | |
| 65 | Ял көне<br>Кабатлау | 1<br>1 | Ял, ял көне<br>Өйрәнелгән материалның истә калуын бәяләү. | Ял итү һәм аның кирәклеген физиология аша аңлау<br>Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Ял көнен үткәрү турында сөйли алу.<br>Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Файдалы ял итә белү.<br>Дәресләрдә кызыксынучан булу. | Аудиоматериал белән эш. “Оркестр”, “Кар өеме”, “Сорау- җавап” һ.б. уеннарны уйнау. Җыр башкару<br>“Ел фасыллары”, “Көндәлек режим”, “Тәүлек” биремнәрен үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Карточкалар белән эш.<br>Уен форматында 3 бирем башкару. | |
| 66 | Тикшерү һәм бәяләү | 1 | Ел дәвамында өйрәнелгән материалның истә калуын бәяләү. | Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу. | Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу. | Дәресләрдә кызыксынучан булу. | Лексиканы белү, сөйли алу һәм сорау бирүгә караган биремнәрне үтәү. Үз-үзеңне һәм сыйныфташларыңны бәяләү. Хаталар өстендә эш. | Уен форматында 3 бирем башкару. | |

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ "АНТОНОВСКАЯ СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН",** Вихлянский Александр Николаевич, Директор

**30.09.24** 21:14 (MSK)

Сертификат 2DBFDEFD1F2A102C7DFFD3DF2EC85E13